**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №184-32 «28» май 2024 ел.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2023 елның 18 апрелендәге 127-21 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендәге кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан аредалана торган һәм шәхси эшкуарлар булмаган һәм «Профессиональ керемгә салым "махсус салым режимын кулланучы физик затлар тарафыннан арендалана торган күчемсез милекне читләштерү турындагы Нигезләмәне раслау хакында"гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон (06.04.2024 редакциясендә) нигезендә:

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2023 елның 18 апрелендәге 127-21 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендәге кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан аредалана торган һәм шәхси эшкуарлар булмаган һәм «Профессиональ керемгә салым "махсус салым режимын кулланучы физик затлар тарафыннан арендалана торган күчемсез милекне читләштерү турындагы Нигезләмәне раслау хакында"гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.1 пунктындагы 3.1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Арендага алынган күчемсез милек "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлешенә яраклы рәвештә расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына милеккә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән дәүләт милке яки муниципаль милек исемлегенә кертелмәгән, һәм 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 2.1 өлешендә каралган очрактан тыш, гариза бирелгән көнгә кадәр килешү нигезендә бер ел һәм аннан да күбрәк вакытлыча файдаланудa була.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин